**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Верхнестярлинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Югары Стәрл авыл жирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**

**ул. Советская, д.32г, с. Верхнее Стярле, 423314**
**Азнакаевского муниципального района**
**Тел.факс (8-5592) 42618,**
**VSt.Azn@tatar.ru**

**Совет урамы, 32г, Югары Стәрле авыл**
**423314**
**Тел.факс (8-5592) 42-6-18,**
**VSt..Azn@tatar.ru**

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

## КАРАР

«01» ноябрь 2019 ел

№ 2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Түбән Стәрле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруныц гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. 20.11.2019 ел Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Түбән Стәрле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Балан – Бүләкторак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 20 ноябрь 2019 ел 10.00 сәг.тән 11.00 сәг.кадәр;
- үткәрү урыны – Түбән Стәрле авылы, Кызыл тан ур. , 42Г йорт, Түбән Стәрле ФАПы.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 5 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түбән Стәрле авылы, Кызыл тан урамы, 42А йорт;
- сайлау хокукына ия булган Түбән Стәрле торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Түбән Стәрле торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 Югары Стәрле авыл җирлеге Түбән Стәрле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны 2 төркем инвалидлар өчен 150 сум итеп билгеләргә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау ( Түбән Стәрле авылында юлларны грейдерлау);

- Түбән Стәрле авылында юлларны кардан чистарту;

- Түбән Стәрле авылында территорияләрне чүп үләннәреннән һәм чүп-чардан чистарту хезмәтләре;;

- бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар көне», «Яңа ел " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү;»;

« РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Совет ур., 32г адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: Л.С.Сабиржанова